СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 5-30 от «27» мая 2024 г.

”Янгын күзәтчелегенең социаль юнәлешле иҗтимагый берләшмәләренә һәм ирекле янгын сүндерүчеләргә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында" 2012 елның 23 апрелендәге 10-12 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Ирекле янгын күзәтчелеге турында" 2011 елның 6 маендагы 100-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында ирекле янгын күзәтчелеге турында" 2011 елның 1 августындагы № 48-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, 2023 елның 16 ноябрендәге «Татарстан Республикасында ирекле янгын күзәтчелеге турында "Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 110-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Мамадыш муниципаль районында ирекле янгын күзәтчелеген үстерү өчен кирәкле шартлар тудыру максатында Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. ”Янгын күзәтчелегенең социаль юнәлешле иҗтимагый берләшмәләренә һәм ирекле янгын сүндерүчеләргә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында" 2012 елның 23 апрелендәге 10-12 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы карарына( алга таба-карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 2 абзацында "эшчеләр һәм ирекләләр" сүзләрен "ирекле янгын сүндерүчеләр һәм ирекле янгын күзәтчелеге хезмәткәрләре"сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны Район башлыгы урынбасары, муниципаль район Советы Рәисе урынбасары Р.Р.Сәмигуллинга йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П. Иванов